**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2023 елның 31 гыйнвары 21-РС номер

# КАРАР

## «Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 11 сентябрендәге 52-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законны, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 2013елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы карарын үтәү максатыннан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар итте:

1. Лаеш муниципаль районы Советының 2015 елның 11 сентябрендәге 52-РС (2018 елның 12 декабрендәге 65-РС номерлы соңгы үзгәрешләр белән) карары белән расланган Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Нигезләмәнең 11 пунктында:

1.1.1. 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән форма буенча үз куллары белән тутырылган һәм имзаланган анкета;»;

1.1.2. 3 нче пунктның 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- хезмәт кенәгәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән мәгълүматлар, хезмәт килешүе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

1.1.3. 4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, индивидуаль (персонификацияләнгән) исәп-хисап системасында теркәлүне раслаучы документ;»;

1.1.4. 7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләү өчен документлар тапшырылганчы керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук контракт буенча бер ел эчендә хатынының (тормыш иптәшенең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр»;

1.2. Нигезләмәгә кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль Советы аппараты җитәкчесе А.Ә.Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**